

Мордовия татарлары арасында олы яшьтәгеләр байтак. Шулай, Кадошкино районы Латышовка авылында яшәvче 100-яшьлеклеләр турында да яздык. Ә бvген, шул ук авыл кешесе - Шамиль Хосәен улы Емагулов Россия Президенты В.В.Путиннын юбилеена багышланган котлавын алды. Ана 95 яшь тулды.      Аны котларга район һәм авыл хакимияте, халыкны социаль яклау, район һәм жирле ветераннар Советы, жәмәгатьчелек вәкилләре килгән иде. Бер кешенен туган коне хәтта латышлылар очен дә истәлекле булды. Эш шунда ки, Шамиль Хосәен улы авылнын хормәтле кешесе, Боек Ватан сугышы ветераны. Һәр латышлы vзенен рәхмәт сvзләрен, хормәтен, озын гомер теләвен белдерvгә бик шат. Шуна кvрә кунакларны һәрчак кабул итәргә яраткан Емагуловлар йортында бу конне бәйрәм булды. Хужабикә Сара Исмаил кызы ойләрендә шундый гореф - гадәтне булдырган һәм яратып кунакларны каршы ала, ә соекле әниләренен дәвамчылары оч кызы - Алия, Әлфия, Голфирә. Оныклары белән онықчыклары да бер-берсе белән дус яши.
Шамиль Хосәен улы шундый матур озын гомерне гаиләсе, vз-vзе, намусы белән тату гомер кичерә. Бу хәлне барысы да билгеләп vтә. Кvпләргә vрнәк булырлык кешеләр арасында ул да бар. Шамиль Хосәенович беркайчан да тәмәке дә тартмаган. Кешене vпкәләтмәс очен сvзен дә сайлап кына әйтә. Балаларга тавыш кvтәрми, ул һәркемне - кечкенә булсынмы, яшьтәшеме - хормәт итә. Шуна да ул авылдашлары хормәтенә лаек. Шамиль Хосәен улы Емагулов туган Латышовкасыннан сугышка китә, шунда ук әйләнеп тә кайта. Гомер буе авылы колхозында хезмәт итә; барлык татарлар яраткан атлар тирәсендә. Хужабикә Сара апа да колхозда, кырчылыкта тырышып эшли. Юбилярыбыз - Кече Ватан патриоты. Анын юлы кая гына барса да, туган йортына әйләнеп кайта. Әлбәттә, кайчандыр кочле булган жилкәләре, еллар озынлыгыннан тошкән, әмма ветеран бирешми. Ул һәрвакыт кәефтә; иске гадәт буенча, кызларына кvнеленен тирән почмагында саклаланган татар жырларын жырлый. Алар балачактан әтиләренен нинди генә авыр вакытлары булмасын, жырлавын хәтерли. Шулай барлык ойдәгеләрне рухландырып: барысы да, һичшиксез, яхшы булачак, дип ышандыра. Хәзер дә ул барысына да бары яхшылык кына тели, кызлары да анын янәшәсендә бәхетлерәк. Алар балаларында «әтиләре»нен дәвамын шатланып кvреп алалар.
Бәхетле озын гомер итегез, дигән матур теләктә барчасы!